КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 18 май г.Казань № б-998

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «2024 елда Татарстан Республикасы сәнәгате һәм кулланучылар базары эшенә йомгаклар һәм 2025 елга бурычлар. Җитештерүләрнең нәтиҗәлелеген арттыруда заманча алымнар» дигән коллегия утырышы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнехановның 2025 елның 11 апрелендәге ПР-66 номерлы йөкләмәләр исемлегенең 1.8 пунктын үтәү максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән Россия Федерациясе Президентының «Фәнни-технологик үсешнең өстенлекле юнәлешләрен һәм фән казанышларына нигезләнгән иң мөһим технологияләр исемлеген раслау турында» 2024 елның 18 июнендәге 529 номерлы Указы белән расланган фәнни-технологик үсешнең өстенлекле юнәлешләре һәм фән казанышларына нигезләнгән иң мөһим технологияләрне гамәлгә кертү өчен кадрларны алдан әзерләүгә тармак заказын формалаштыру буенча чаралар планын («юл картасын») расларга.
2. Әлеге боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән чаралар планы пунктларын үтәү өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнарына һәм оешмаларга, хисап аеннан соң килә торган айның 5еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына хисап мәгълүматын кертергә.
3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин